СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**04 октябрь 2016 ел** **№ 22**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 30 сентябрендәге 16 номерлы «Референдум үткәрүне оештыру турында» гы Карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 21 номерлы «Референдум үткәрүне оештыру турында» гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2017 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- янгын гидранты урнаштыру: Штерә авылы, Ашабаш авылы
- юлларга вак таш җәю: Иске Чүриле авылы (Яшел ур.), Ашабаш авылы (Күпер ур.), Штерә авылы (Совет ур.)
- чишмә территориясен төзекләндерү: Ермоловка авылы;

- зират коймасын алыштыру: Иске Чүриле авылы (мәйданы 150 м);
- зират өчен металл плагин сатып алу: Татар Кадрәк авылы (мәйданы 150 м);
- Штерә авылында урамнарны яктырту

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа 52; ТР, Арча районы, Штерә авылы, Совет урамы, 30; ТР, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а йорт; ТР, Арча районы, Венета авылы, Үзәк урамы, 13 йорт, мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина

СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012646